е

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КНӘЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

20.12.2019 ел Татарстан совхозы поселогы № 124

Кнәз авыл җирлеге территориясендә пиротехник эшләнмәләрне куллану урынын билгеләү турында

Яңа ел бәйрәм чараларының, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген, физик һәм юридик затлар мөлкәтенең, дәүләт яисә муниципаль милекнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» турында 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Яңа ел һәм Раштуа чаралары чорында Кнәз авыл җирлеге территориясендә махсуслаштырылган кибетләрдә яисә кибетләрнең махсуслаштырылган бүлекләрендә иркле сатуда булган I-III класслы хәвефлелектәге (хәвефле зона радиусы 0,5 метрдан 20 метрга кадәр) көнкүреш пиротехника эшләнмәләрен авыл халкы тарафыннан куллану урынын түбәндәге территорияләрдә билгеләргә:

- Татарстан совхозы поселогда Куликовка урамы ;

- Сосновый Бор поселогонда , " Сабантуй “бәйрәме үткәрү урыны ;

- Кнез авылында 108 йорты каршындагы мәйданчыклары;

- Казиле авылында, Механический урамындагы мәйданчыклары;

- Черщелы авылында, Луговой переулогандагы мәйданчыклары;

2. Пиротехника әйберләрен эшләтеп җибәрү өчен мәйданчыкларны кирәкле күләмдә беренчел янгын сүндерү чаралар белән тәэмин итәргә, шулай ук гражданнар көнкүреш пиротехника эшләнмәләрен кулланганда куркынычсызлык чараларын үтәү буенча инструкцияләр урнаштырылган мәгълүмати стендлар белән җиһазландырырга.

3. Әлеге карарны Кнәз авыл җирлегенең махсуслаштырылган мәгълүмат стендларында, районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Т.И.Белова

ОГРН 1061682004515 Исполнительный комитет КНЯЗЕВСКОГО сельского поселения ИНН 1639032295